**СОВЕТ**
**АКБУРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Октябрьская, д. 44,
с. Акбуре, 423197

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКБҮРЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Октябрь урамы,44 нче йорт
Акбүре авылы, 423197

тел.: (8-84348) 3-62-40, факс: (8-84348)3-62-40, Akbur.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2020 елның «2» ноябреннән № 2

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегенең Акбуре авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Акбуре авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте**:**

1. 2020 елның 29 ноябренә сәгать 10.00 да авыл мәдәният йортында (Совет ур., 30) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге Акбүре авылында үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә
2. 2020 елның 29 ноябренә сәгать 14. 00 да авыл мәдәният йортында (Совет ур., 30) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге Акбүре авылында үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Акбуре халкы исемлеген сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
4. Гражданнар җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегенең Акбуре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, 1 төркем инвалидлардан кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Акбуре территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, Октябрь урамы буенча чокыр аша чыгу

юлын төзү (материал сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү системасын һәм инфраструктура объектларын проектлау, ремонтлау, карап тоту (сатып алу), килешү буенча эшләр өчен түләү, техник документацияне эшләү, хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү) өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегенең Акбуре бистәсе авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акбуре авыл җирлеге башлыгы Җ.М.Җәләлетдинов